**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ МОРДОВСКО-АФОНКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКЭСЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423103, Мордва Афонькэсе авылы, Цаплин урамы, 19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru

---

16 май 2025 ел № 165

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә

ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы карарына (Советның 24.08.2018 ел № 88, 13.11.2018 ел № 92, 22.10.2020 ел № 8, 17.11.2022 ел № 78, 31.01.2023 ел №86, 19.06.2024 ел № 129, 26.12.2024 ел №156 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы 3 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләме 15389 сум тәшкил итә»;

1.2. 1 нче кушымтада III бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәгечә бәян итәргә: «6) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның 58 процентыннан артмаган күләмдә.»

1.3. 7 нче кушымтаның 1 пунктын бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш ай саен акчалата бүләкләү түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә ай саен акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи окладның 58 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә»;

1.4. «2 нче кушымтада «Үз вәкаләтләрен авыл җирлегендә даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәрен» 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.5. 1 нче кушымтаның I бүлегенең 3 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә: «Авыл җирлеге башлыгына ай саен акчалата бүләкләү түләнә. Күрсәтелгән затларның хезмәтенә түләү чыгымнары күләме айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә елына 15,48 айлык акчалата бүләкләүләр бүлекләре өчен нормативтан артыграк була алмый»

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.И.Митяев

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының
2025 елның 16 маендагы
№ 166 карарына 1 нче кушымта

Үз вәкаләтләрен авыл җирлегендә даими нигездә гамәлгә ашыручы
авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 21091,00 |